*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

**Дүртенче сан** **Декабрь, 2015 нче ел**

*Мөслим гимназиясе базасында уздырылган “Башлангыч сыйныфларда укучы-укытучы хезмәттәшлеген оештыру” регионара семинар-киңәшмәсенә багышланган махсус чыгарылыш*

### КОЛЛЕКТИВ ТУРЫНДА САНЛЫ АҢЛАТМА

| | |
|---|---|
| *РФ гомуми белем бирү мәктәпләренең Почетлы хезмәткәре* | 1 |
| *«ТР физик тәрбия һәм спорт отличнигы» күкрәк билгесе* | 1 |
| *ТР ның «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе* | 6 |
| *РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Почет грамотасы* | 7 |
| *ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Почет грамотасы* | 8 |
| *“Мәгариф” өстенлекле проекты җиңүчеләре* | 4 |
| *ТР 2010-2015 нче елларга мәгариф стратегиясен тормышка ашыручы “Иң яхшы укытучы” гранты* | 16 |
| *Югары квалификацион категорияле укытучылар* | 19 |
| *Беренче квалификацион категорияле укытучылар* | 16 |

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ



***Мирзаянов Азат Фәрит улы - Мөслим гимназиясе директоры:***

*XXI гасыр – инновацияләр гасыры. Укучыларның белем дәрәҗәсе заман белән бергә атларга тиеш. «Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге» буларак, гимназиядә укыту-тәрбия процессы югары информацион технологияләргә таянып оештырыла. Барлык укытучыларның һөнәри, педагогик-психологик, методик, информацион-коммуникатив яктан компетентлы булуы мине куандыра.*

*Киләчәктә Мөслим гимназиясе республикада гомуми белем бирүче инновацион уку йортлары арасында лаеклы үз урынын табар, дип ышанам.*

***Заялова Лира Нурфаяз кызы - Мөслим гимназиясенең укыту эшләре буенча директор урынбасары:***



Уку йортының статусын билгели торган критерий – ул белем сыйфаты. Гимназиядә алган тирән белемнәр укучыларыбызга тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итсен иде. “Беләге юан – берне егар, белеме булган – меңне егар” дигән халык мәкале бүгенге көн өчен дә актуаль, минемчә. Фән бәйгеләрендә, фәнни-практик конференцияләрдә, бердәм дәүләт имтиханнарында гимназия укучылары бу хакыйкатьне раслап киләләр. Мөслим гимназиясе укучысы дигән исемне горур йөртегез, тырышып укыгыз. Яңа ел барыбыз өчен дә уңышлар елы булсын!

***Хәбирова Сәвия Закирҗан кызы - Мөслим гимназиясенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары:***



Киләчәк – балалар кулында. Гимназиядә “Тормыш дәресләре” темасы астында төрле тәрбия чаралары үткәрелә. Аларда районыбызның күренекле шәхесләре, сугыш һәм хезмәт ветераннары, төрле чорларда үзләре пионер, комсомол лидерлары булган активистлар катнаша. Мондый дәресләрнең әһәмияте зур. Программага таянып, укучыларда милләтпәрвәрлек хисләре уятырга, туган җиргә, Ватанга, телебезгә ихтирам тәрбияләргә омтылабыз. Гимназияне тәмамлаган укучылар Мөслимебез елъязмасында матур эшләре белән урын алырлар.

***Мәрданшина Рушания Мөхтәр кызы - Мөслим гимназиясенең методик эшләр буенча директор урынбасары:***



Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан куелган белем сыйфатын күтәрү таләбен тормышка ашыру өчен, укучыларга да, укытучыларга да кулай булырдай яңа алымнар уйлап табарга кирәк. Коллективка компетентлы белгечләр - үз эшенең осталары тупланган. Һәрбер фән иясенең тәҗрибә белән сыналган, үзенә генә хас булган эш алымнары, табышлары, отышлы методикалары бар. Шуларны исәпкә алып, максатчан эш оештырганда, хезмәтебез нәтиҗәле булыр, дип уйлыйм.

## ГИМНАЗИЯ БҮГЕН

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – Россия “Милли мәгариф” проекты җиңүчесе – 2008.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – “Укучыларның туклануын оештыру буенча иң яхшы мәктәп ашханәсе” VI Республика конкурсы җиңүчесе - 2009.



БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – медицина кабинетларының Республика смотр-конкурсы җиңүчесе - 2014.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – “Сәламәтлек саклау юнәлешендә “Алтын дәрәҗә”ле мәктәп” квалификацион характеристикасына ия булган уку йорты - 2014.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – 445 укучы, 48 укытучы бердәм эшләүче коллектив.

## МОГҖИЗАЛЫ УНЛЫК

***Ләйсән Әхмәтгаяновна, сезнеңчә, “чын укытучы” нинди булырга тиеш?***

Чын укытучы үзенең һөнәре белән янарга һәм авырырга тиеш. Минем фикеремчә, яхшы укытучы булу өчен белемле булу гына аз, ә тәнеңдәге бөтен күзәнәгең аша син үзеңне укытучы итеп тоя белергә дә тиеш. Укытучы күпмедер күләмдә актер да әле. Ул ”сәхнәгә” үзенең шәхси борчуларын чыгармаска тиеш. Шуңа да мин, тормышымда нинди генә авырлыклар булса да, класска һәрвакыт ачык йөз, шат елмаю, якты кәеф белән керергә тырышам.

***Сезнең укытучы һөнәренә карашыгыз нинди?***

“Укытучы оста артист, ләкин аңа кул чапмыйлар, ул оста скульптор, ләкин аны күрмиләр, ул яхшы табиб, ләкин аңа пациентлары дәвалаган өчен бик сирәк рәхмәт әйтә, кайберәүләре, кайвакыт, дәваланырга да теләми. Ә рухлану өчен кайдан көч алырга соң? Бары тик үзеңнән, үзеңнең хезмәтеңнең бөеклегеннән,”- дигән танылган язучы С.Л. Соловейчик. Әйе, укучыларымны шатландырып, күңелләрен күреп, ихласлыкларын сүндермичә, белемгә кызыксыну уятып, эшләргә дә эшләргә....

***Сезнең нинди өметләр белән яшисез?***



*Фәхертдинова Ләйсән Әхмәтгаян кызы*

Мин укучыларыма ышанычлы терәк, сердәш булырга телим. Иҗади якын килеп эшләргә тырышам. Үзеңнең куйган хезмәтеңнең нәтиҗәсен күрү өчен бик сабыр булырга, иң катлаулы ситуацияләрдә дә оптимист булып калырга, кешелеклелек сыйфатларын югалтмаска кирәк. Ышанып әйтә алам: мине алга таба да бик кызыклы педагогик тормыш көтә.



*Латыйпова Ирина Владимирна*

***Ирина Владимировна, сез ни өчен укытучы һөнәрен сайладыгыз?***

Безнең гаилә – укытучылар гаиләсе. Мөслимлеләрнең күбесе яраткан укытучылары дип йөрәк түрләрендә йөрткән Тазова Мария Кузьминична - минем әбием, Николай Васильевич - бабам, Надежда Николаевна - әнием, Юрий Николаевич – абыем. Гомумән, династиянең эш стажы йөз кырык елдан артып китә. Мондый тирәлектә үсеп, башка һөнәр сайлау мөмкин дә түгелдер.

***Башлангыч сыйныфларда эшләүнең кайсы ягы сезне үзенә тарта?***

Беренче сыйныфка укырга килгән бала - ак кәгазь бите кебек чиста, саф. Шул аклыкны саклаган хәлдә, сабыйны белем дөньясы буйлап сәяхәткә алып чыгасың. Дүрт ел дәвамында кулга-кул тотынып эшләү нәтиҗәсендә, бала үзлектән белем алырлык дәрәҗәдә мәгълүматлы, төрле шартларда син биргән белемнәрне кулланырлык дәрәҗәдә креатив, югары әхлакый сыйфатларга ия булган чын шәхес булып формалаша. Үзең тәрбияләгән, белем биргән укучыларның уңышы – ул синең дә уңышың!

***Алсу Рауиловна, һөнәргә килу юлыгыз турында сөйләгез әле.***

Мин кечкенә вакытта “укытучылы” уйнарга ярата идем. Газетаның эре хәрефләрен кисеп, күрше кызын укырга өйрәтәм, мисаллар чишәбез. Шул уеннан бүгенге көндә дә арына алмыйм. Яшьлегемдә югары сыйныф укучылары белән рәхәтләнеп эшләдем, хәзер башлангыч сыйныфларда укытучы буларак үземне таптым.



*Гомәрова Алсу Рауил кызы*

***Нинди принциплар белән эшлисез?*** Бала — шәхес, аңа үз тиңең итеп карарга кирәк. Минемчә, укытучы үз балалары белән бергә үсә. Үз балаларыма нинди тәрбия бирер идем, дигән уй минем башымнан чыкмый. Укыту-тәрбия эшчәнлеген шул күзлектән чыгып оештырам.

***Гөлчәчәк Фирдависовна, тәрбиячеләр, гадәттә, “Укучы – Укытучы – Ата-ана” өчпочмагы турында сөйләргә яраталар. Моңа сезнең карашыгыз ничек?***

Гаилә һәм мәктәп бер кадакка сукканда, теләсә нинди авырлыкларны җиңәргә була, минемчә. Үз хезмәтемне мин халык педагогикасына, гаилә традицияләренә таянып башкарам. Укучыларымның өлкәннәргә игътибарлы, кешелекле булуларын телим.



**Исмәгыйлова Гөлчәчәк Фирдәвис кызы**

***Бүгенге укытучыга карата таләпләрегез нинди?***

Заман укытучыга үз таләпләрен куя. Минемчә, бүгенге укытучыга белемле булу гына аз. Ул инициативалы, актив, креатив шәхес булырга тиеш. Һәртөрле мәгълүмат белән тиешле дәрәҗәдә эшли белмәсәң, бүгенге информация ташкынында югалып калуың бар.



**Ермолаева Эльвира Сабирҗан кызы**

***Эльвира Сабирҗановна, сезнең укучыларыгыз гимназия тормышында актив, инициативалы булулары белән аерылып торалар. Бу очраклы хәлме?***

Безнең сыйныфта һәрвакыт тигез мөнәсәбәтләр хакимлек итә. Коллективның һәр әгъзасы үз фикерен курыкмыйча әйтергә хокуклы. Теләсә нинди фикерне тыңлыйбыз, кабул итәбез. Инициатива хуплана. Ошамаса, такт саклап кына кире кагабыз. Укучыларда иҗади активлык, дустанә мөнәсәбәтләр, аралашу культурасы тәрбияләүгә игътибар итәм.

***Укучылар белән нинди проектлар тормышка ашырыла?***

Без сәламәтлек юнәлешендәге “Здоровейка” дәрестән тыш шөгыль проекты өстендә эшлибез. Һәр айда нәтиҗәләр ясап барабыз. Үз хезмәтемдә ата-аналарның ярдәменә таянып эшлим. Бөтен бәйрәмнәрне бергәләп оештырырга күнектек. Сыйныф бүлмәсен конкурска әзерләгәндә дә аларның ярдәме күләмле булды, чыгышлар өчен костюмнар тегү, маскалар ясау кебек эшләрне дә бергә башкарабыз.

## МОГҖИЗАЛЫ УНЛЫК

***Ләйсән Габбасовна, сезнең турда “иң тыныч холыклы укытучы” дип әйтер идем мин. Мондый сыйфатыгыз каян килә дип уйлыйсыз?***

Һәр кеше үзенең беренче укытучысын хәтерли. Мин Тугаш башлангыч мәктәбенә 6 яшьтән укырга кердем. Укытучым Нәгыймә апаның ялтыравыклы сумкасына гашыйк идем. Көн буена өстәлдә торган шул сумкадан күземне алмый идем. Укытучымның киеме дә, үзе дә, гадәтләре дә ошый иде. Аның тыныч холкы, салмак хәрәкәтләре, ягымлы тавышы бүгенгедәй күз алдымда тора. Аның кебек сабыр, тыныч укытучы буласым килде.

***Укучы балалары булган яшь гаиләләргә нинди теләкләрегез бар?***

Бүгенге гаиләләрдә бергәләп аралашу җитми. Кич белән һәр кеше я компьютер артында, я телефонда, я телевизор алдында вакыт уздыра. Без кечкенә вакытта әтинең гармун уйнаганына барыбыз җыелып бии, җырлый идек. Мондый кичләрне хәзер дәниндидер бер рәхәтлек белән искә алам. Гаиләдә җылы мөнәсәбәтләр булуын, җанлы аралашу булуын теләр идем.



**Мортазина Ләйсән Габбас кызы**



**Идиатуллина Маргарита Александровна**

***Башлангыч сыйныф укытучысы булу өчен махсус белем булу гына җитми, сәләт тә кирәк. Сезгә укытучылык сәләте кайсы яктан бирелгән?***

Безнең нәселдә укытучылар һәм юристлар күп. Сәләт, әлбәттә, әти-әнидән күчкәндер, дип саныйм мин. Башка балалар арасында бик таләпчән икәнемне, гаделлек яратуымны күреп, әнием судья булуымны теләде. Үземнең дә андый уйларым бар иде. Апам Виктория Александровнаны нык ярата идем. Ул Минзәлә педагогия училищесына укырга кергәч, мин дә аның артыннан училищега киттем. Шулай итеп, ничектер үзеннән-үзе һөнәр сайлау мәсьәләсе хәл ителде дә куйды.

***Бүгенге заман укучысына мөнәсәбәтегез нинди?***

Мин укучыларымны учымдагы нәни кошчыклар итеп хис итәм. Канат куеп, ныгыткач, аларны оядан очыра барам. 37 ел эшләү дәверендә күпме оя балалар белән эшләргә туры килде?! Һ ә р бала – үзе бер нәни дөнья. Балаларны ятратканда гына нәтиҗәләргә ирешеп була.



**Мирзасалихова Гөлназ Шәйдулла кызы**

***Без сезне үз һөнәренә бирелгән иҗади шәхес буларак беләбез. Сезнең үз фикерегез ничек?***

Әйе, укучыларымны, үз һөнәремне бик яратам. Катлаулы булса да, кызыклы һәм бик тә кирәкле һөнәр бит ул. Хезмәтемдә иҗади үсеш технологиясен кулланам. Максатым: укучыларның иҗади активлыкларын үстерү. Минемчә, һәр укучы үз фикерен төгәл итеп әйтеп бирергә, дөрес аралаша белергә тиеш.

Иҗат итү минем хезмәтемне тулыландыра, мавыктыргыч итә. Шигырь язу серләренә укучыларны да төшендерергә телим. Яңа җырлар ишетсәм, битараф кала алмыйм, отып алып өйрәнергә тырышам. Үзем иҗат иткән шигырьләр җыентыгым бар. Илгиз Закиров шигыремә җыр язды.



**Рәхмәтуллина Алсу Расих кызы**

17 ел педагогик хезмәтемнең бер өлешен балалар бакчасында тәрбияче буларак, икенче өлешен башлангыч сыйныфлар укытучысы буларак карарга булыр иде. Мин мондый тәҗрибәм булуы белән горурланам. Бу - бала шәхесенең формалашу этапларын тулы итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә торган хәзинә. Логопедия, психология буенча белемнәрем мәктәптә балалар белән нәтиҗәле эшләргә ярдәм итә. Мин шәхескә йогынты ясауның камил юлларын эзлим, укучыларымны чиста күңелле, эчкерсез, ярдәмчел итеп күрәсем килә.

Сәламәтлек - иң зур байлык. Күп тапкыр кабатланган фраза булса да, ул һәрвакыт актуаль. Башлангыч сыйныфларда физик тәрбия буенча төп күнекмәләр бирелә. Дәресләргә укучылар бик яратып йөриләр. Үзем дә кече яшьтәге укучылар белән чын күңелемнән бирелеп, яратып эшлим.

Хезмәтемнең нәтиҗәләре дә куанырлык: гимназиянең футбол командасы район ярышында беренчелекне бирми. Шәхси беренчелектә җиңел атлетика, чаңгы буенча уңышларыбыз бар.



**Хантимеров Руслан Риф улы**

***Гүзәлия Әнвәровна, сезне һәрвакыт төрле яшьтәге балалар уратып алган була, үзегез дә шулар белән мәш килеп йөрисез. Озайтылган көн төркемендә теләсә кем эшли алами?***

Озайтылган көн төркемнәре – үзенчәлекле хезмәт таләп итә торган өлкә. Балалар сине үз әниләре кебек хис итәләр. Бу – табигый да! Көннең икенче яртысында, күпчелек укучы өйдә ата-анасы янында була торган вакытта, безнең төркемдәге балалар - минем янда. Бала күңеле бик сизгер. Бернинди борчу сизмәсеннәр өчен, бала да, ата-ана да, укытучы да канәгать булсын өчен тырышам.

Режим буенча эш ялыктыргыч булмасын дисәң, фантазияне эшкә җигәргә туры килә, укучыларның теләген дә исәпкә алырга кирәк. Хезмәтем җаваплы, шактый катлаулы, зур сабырлык сорый. Башлангыч сыйныфларда укыту тәҗрибәм булу, балаларны чиксез ярату миңа көч бирә.



**Нигимаева Гүзәлия Әнвәр кызы**

# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

## Ә бездә театр!



Гимназиянең актлар залында башлангыч сыйныф укучылары өчен театр-тамаша күрсәтелде. "Балкыш" театр түгәрәгенә 6-8 нче сыйныф укучылары йөри. Нәниләр өчен тамашаны түгәрәк җитәкчесе Ямалова Г.Ф. әзерләде.

## Китап яратучылар



"Әдәбият елы" кысаларында район күләмендә "Китап ярминкәсе" уздырылды. Мәллә башлангыч мәктәбе беренче, Мөслим гимназиясе "Иң күп китап сатып алучы мәктәп" номинациясендә 2 нче урын алды һәм 1500 сумлык сертификатка лаек булды.

Шәхси номинацияләрдә җиңүчеләр: Солтанова Алия (4б), Миннегалиев Әмир (7б), Хәертдинов Ранис (3б).

Җиңүче класс: 4б сыйныфы (җитәкчесе - Исмәгыйлова Г.Ф.).

## Игелеккә чикләр юк



Инвалидлар декадасы кысаларында "Игелеккә чикләр юк" исеме астында класс сәгате үтте. Укучылар мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә карата кайгыртучан, шәфкатьле булуларын үз тормышларыннан мисаллар белән исбат иттеләр.

## КИТАП – ТОРМЫШ СУЛЫШЫ



Районыбызда "Әдәбият елы" уңаеннан 1 ноябрьдән 30 ноябрьгә кадәр китап пропагандалау, тарату, сату айлыгы игълан ителде.

Гимназиядә дә шаулап-гөрләп китап ярминкәсе үтте. Шәхси эшмәкәр Рәмилә апа Дәүләтова иртән үк гимназия фойесына килеп урнашты. Ул сатарга күп итеп төрле-төрле берсеннән-берсе матур китаплар алып килгән иде. Һәр класс укучысы үзенә охшаган китапны сатып алды. Мин һәм сыйныфташларым әдәби китаплар белән бергә кагыйдәләр җыентыклары, төрле уку ярдәмлекләре алдык.

2 декабрьдә китап сату айлыгына нәтиҗә ясалды. Безнең гимназия район буенча икенче урынга чыкса, 4б сыйныфы беренчелеккә ия булды, 500 сумлык сертификат белән бүләкләнде. Мин үзем дә район буенча 1 урынны алдым һәм 400 сумлык сертификатка ия булдым: үземә ошаган китаплар алу хокукын яуладым.

Әйе, китаплар - акыллы киңәшчеләр. Китап укудан да күңелле нәрсә юк, минемчә. Үземә аеруча ошаган китапларны кат-кат укыйсы, алар турында иптәшләргә сөйлисе килә.

Дуслар, матур әдәбият белән дус булыгыз!

***Алия Солтанова, 4 нче б сыйныфы укучысы***

## БӘХЕТЛЕ БАЛАЧАК



Безнең гимназиядә күптән түгел генә сәнгатьле шигырь сөйләү буенча "Бәхетле балачак - Счастливое детство" дип аталган район конурсы булып узды. Бу бәйгедә бик күп укучылар көч сынашты, алар төрле мәктәпләрдән, төрле авыллардан килгәннәр иде. Кызлар һәм малайлар шигырьләрне татар телендә дә, рус телендә дә сәнгатьле итеп сөйләделәр. Мин үземнең шигырьне рус телендә сөйләдем һәм бу бәйгедә 3 нче урынны алдым. Призлы урын алуым белән мин укытучым Ләйсән Әхмәтгаяновнага рәхмәтлемен. Ул мине сәнгатьле итеп шигырь сөйләргә өйрәтте. Мондый конкурслар еш булып торсын иде, без бик теләп катнашыр идек.

***Газетдинова Азалия, 1б***

## ЯРМИНКӘ



Минем исемем Ралина. Быел мин 1 нче сыйныф укучысы булдым. Мәктәптән башта бик курыккан идем. Ә монда бик кызык икән бит! Гел укып кына утырмыйлар, әллә нинди күңелле һәм кызыклы чаралар да үткәрергә җитешәләр.

Күптән түгел гимназиядә башлангыч сыйныф укучылары атналыгы булып узды. Атнаның бер көнендә ярминкә оештырдылар. Һәр укучы ни дә булса пешереп алып килергә тиеш иде. Без, 1в сыйныфы укучылары да, беренче тапкыр бу ярминкәдә катнаштык. Барыбыз да тәмле-тәмле әйберләр пешереп алып килдек.

Миңа ярминкә бик ошады. Өйгә кайткач, әни белән бергәләп, нәрсә пешерергә икән, дип уйлаша башладык. Аннары камырның эченә алма тыгып, бәләкәй кабартмалар пешердек. Бик тиз генә, бер-беребезгә булыша-булыша, кабартмаларыбызны пешереп тә бетердек.

Икенче көнне аларны сатып басып торуы аеруча ошады. Үзебездән зур абый-апаларга саткач, бигрәк кызык икән. Акча санарга да остардым. Ә ярминкәдән кергән акчага без китаплар сатып алдык.

Менә шулай итеп без, бер көнгә генә булса да, "бизнесменнар" булып алдык.

***Маннанова Ралина, 1 нче в сыйныфы укучысы***

## СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕНДӘ




Сәнгать мәктәбенә йөреп, бик күп һөнәрләргә өйрәнергә була! Без быел рәсем бүлегенә йөри башладык. Җитәкчебез Рәмзия Кәримовна бик оста һәм тәвәккәл кеше. Андый кеше турында "кулыннан гөлләр тама", дип сөйлиләр.Чыннан да, ул безне кул эшләренә, матур, дөрес итеп рәсем ясарга өйрәтә. Төрле төстәге кәгазьләрдән открыткалар, брошкалар, әллә нинди кызыклы әйберләр ясыйбыз! Без чын тылсымчылар кебек! Хәтта кофедан агачлар да ясарга өйрәндек. Көннән-көн төрле һөнәрләргә өйрәнәбез. Үз кулыбыз белән ясаган матур әйберләрне бүләк итеп, туганнарны, дусларны сөендерәбез.

Рәмзия апабыз безне рәсем сәнгатенә генә түгел, ә әдәпле булырга, кешеләр белән матур итеп сөйләшү, аралашу серләренә дә өйрәтә. Киләчәктә без дә аның кебек оста булырга хыялланабыз.

***Хәбибуллина Регина, Мәрданова Камилә, 2 нче б сыйныфы укучылары***

# КЫШ БАБАЙГА ХАТ

*Исәнме, сөекле Кыш бабай!*


*Узган ел син җибәргән тимераяклар бик ошады, алар миңа бераз зуррак иде, быел инде тап-таман! Былтыр гаиләбез белән рәхәтләнеп Мөслимдә катокта шудык. Ишегалдыбызда да боз катырган идек, әтием һәм абыем белән туйганчы хоккей уйнадык.*

*Безнең Мөслим шундый матурланды, килгәч үзең дә шаккатырсың әле. Яңа парклар, балалар мәйданчыклары ясап бетерделәр. Казандагы кебек җәяү генә йөри торган урамнар да бар. Күп кеше хәзер велосипедта элдерә. Минем дә велосипедым бар! Экстрим-парк ясадылар. И-и, нилэр генә юк анда! Минем кебек малайлар-кызлар рәхәтләнә инде шунда уйнап! Роликлы тимераякларда йөрүчеләргә кызыгып карап торам: их, минеке дә булсын иде... Әтидән сорап караган идем дә, ул: "Аның иң шәпләре Кыш бабайда гына була. Әнә, узган елгы тимераякларың үзе шуа. Быел да соңга калмыйча хат язып сал," – диде.*

*Юмарт бабакаем! Миңа бер матур гына, уңайлы гына роликлы тимераяк җибәрә алмассың микән? Аз гына зуррак булса да, бик затлы булмаса да ярый. Әлегә йөри белмим, ләкин өйрәнәчәкмен, чын менә!*

*Кар-бураннарың, чеметкеч салкыннарың белән тизрәк килеп житүеңне көтеп калам. Безгә дигән бүләкләреңне дә онытма, бабакай!*

***Булат Шәрипов, 2 нче а сыйныф укучысы***


Исәнме, Кыш Бабай!
Минем исемем Азалия, миңа 7 яшь. Мин быел 1 нче сыйныфка укырга кердем. Мин тырышып укырга, язарга өйрәнәм, өйдә әниемә булышам. Минем Адилә исемле апам бар. Без биергә, җырларга, уйнарга яратабыз. Озаклавый күңелле бәйрәмнәр җитә. Без әтием, әнием, апам белән чыршы бизәячәкбез.
Кыш Бабай, син безгә бары бәхет, шатлык, уңышлар, тынычлык, күчтәнәчләр алып кил, сәлам белән, Азалия.

*Исәнме, Кыш бабай! Минем иң-иң яраткан бәйрәмем - Яңа ел бәйрәме. Мин аны алдан ук көтә башлыйм.Теләкләремне язып,чыршы төбенә хат язып куям, ә син ел саен бүләк калдырып китәсең. Яңа елда миңа бик күп бүләкләр бирәләр, әмма синең бүләкне мин барысыннан да ныграк яратам! Чөнки ул - синеке, Кыш бабай!*

*Кыш бабай, дөньяда тормыш шартлары бик авыр балалар, хәтта тамагы ач балалар да бар. Син, зинһар өчен, эшең бик күп булып, аларны онытып җибәрә күрмә! Мин Җир йөзендәге барлык балаларның да Яңа елда бүләкле булуын телим!*

*Кыш бабай, без синең шома бозлавыкларыңны, ап-ак карларыңны, бураннарыңны бик яратабыз! Рәхмәт сиңа барысы өчен дә!*

*Сау бул, Кыш бабай! Чыршы бәйрәмендә очрашуны көтеп,* ***Сөмбел Галиева, 2 нче б сыйныфы укучысы.***


*Исәнме Кыш бабай!*


*Сиңа сөенечле хәбәрем бар. Мин быел 1нче сыйныфка укырга кердем. Хәзер мин укый, яза беләм. Сиңа да бу хатны үзем язам.*


*Миңа быел бүләккә чаңгы алып кил әле, Кыш бабай. Бәлки син бүләк итсәң, карлар да күп итеп явар, көннәр дә суытыр иде.*

*Сине дә Яңа ел белән котлыйм һәм кунакка көтеп калам.*

***Фаррахов Ранис, 1 нче в сыйныфы укучысы***






Исәнмесез Кыш Бабай!
Мин Мөслимнән Гадиль булам. Гимназиянең 1б классында укыйм. Мәктәптә әйбәт укырга тырышам. Өйдә әтигә, әнигә булышам.
Кыш Бабай барлыгына ышанам. Син тизерәк килсен дип, әнем белән чыршы бизәп куйдык.
Кыш Бабай теләкләр үти дип ишеткән бар иде. Шуңа, сиңа хат язарга булдым. Минем бик нык тимераякта шуасым килә иде. Алып килә алмассың микән? Сине


## ҮЗЕБЕЗ ӘКИЯТ ЯЗАБЫЗ

### ӘКИЯТЛӘР ИЛЕНДӘ

Мин тылсымлы әкиятләр укырга яратам. Алар мавыктыргыч, кызыклы, яхшылыкка өйрәтә. Әкият укыганда, күңелләр күтәрелеп китә һәм син маҗаралар дөньясына чумасың. Менә син оча торган машина белән кая телисең – шунда барасың. Оча торган келәмнәргә утырып, күз күрмәгән ерак җирләргә сәяхәт итәр идем. Бөтен дөньяны иңләр идем! Ә күзгә күренми торган кеше булсам, мин мин нишләр идем микән? Бәлки көчсезләргә, хәерчеләргә, авыр хәлдә калганнарга булыша алыр идем.

Ә иң ошаганы - әкиятләрдә яхшылык начарлыкны җиңә. Тормышта да шулай булсын иде!

***Мирзаморатов Шәһрәт, 4 нче а сыйныф укучысы***



### Карандаш белән бетергеч

Борын-борын заманда яшәгән, ди, Карандаш. Ул бик оста рәссам булган. Карандашның рәсемнәре ясалып беткәч, аны буяу белән пумала буяган.

Беркөнне болар янына Бетергеч килгән. Ул бик ашарга ярата икән. Карандашның рәсемен “әх” дигәнче юкка чыгарган. Шуннан бирле Карандаш ясый, ә Бетергеч бетерә, ди.

***Бәдретдинов Дамир,***
***4 нче б сыйныфы укучысы***

### Пәри малае Әри

Борын-борын заманда, кара урман уртасында булган икән бер алан. Шул аланда яшәгән, ди, җен-пәриләр. Аларның балалары урман мәктәбендә укыган. Мәктәптә аларны гел начарлыкка өйрәткәннәр. Әри исемле җен малае бик акыллы икән. Ул сугышмаган, каршы сүз әйтмәгән, дәфтәрләре чиста, китаплары тышлы булган. Аның әнисенә: “Әри - яхшы малай, җеннәргә тиң түгел”, - дигәннәр. Күп тә үтмәгән, аны җеннәр арасыннан куганнар. Әнисе аңа урманнан чыгып китәргә булышкан.

Бара торгач, Әри бик матур болынга җиткән.



Анда көтү-көтү мал йөри икән. Ә көтүчесе Әри кебек бер малай булган. Алар дуслашып киткәннәр һәм Әри шунда көтү көтәргә калган.

***Ильясов Рамил,***
***4 нче б сыйныфы укучысы***

### Куян малае



Борын заманда кара урманда яшәгән, ди, куяннар. Алар үзара бик тату булганнар. Ләкин анда бик тыңлаусыз бер куян малае булган. Әти-әнисе нинди эш кушса да, тыңламаган, аның өчен абый-апалары эшләгән. Әти-әнисе моны акылга утыртырга булганнар.

Беркөнне әниләре барсына да тәмле әйберләр алып кайтып өләшкән. Ә теге куян малаена эләкмәгән. Ул бик озак елаган. “Әнием, моннан соң бөтен кушкан эшеңне дә тыңлармын”, - дигән. Шуннан соң абый-апалары белән тырышып эшли башлаган. Алар хәзерге көндә дә матур, тату тормыш итәләр икән.

***Шакирова Диана,***
***4 нче б сыйныфы укучысы***

## ШИГЪРИЯТ СӨЮЧЕЛӘР СӘХИФӘСЕ



# Таң җиледәй әкрен генә назлап,
# Бүген җанны шигырь уятты.

### Дүрт ел гомер

Дүрт ел гомер ашыгып узып киткән,
Дүрт ел гомер - аккан су кебек.
Дүрт ел элек, әйе, дүрт ел элек
Без җиде ят, әле чит идек.

Шушы еллар акыл, белем бирде,
Дүрт ел бирде дусны, иптәшне.
Авыр чаклар булды, җиңеле дә, -
Бер-беребезгә бирдек киңәшне.

Дүрт ел гомер азмы, күпме икән?
Кыскадыр ул уйлап карасаң.
Исең китәр, калган эзләреңә
Бер әйләнеп борылып карасаң.

Дүрт ел гомер ашыгып узып киткән,
Дүрт ел гомер - аккан су кебек.
Дүрт ел элек, әйе, дүрт ел элек
Без җиде ят, әле чит идек.

***Гөлназ Мирзасалихова,***
***башлангыч класслар***
***укытучысы***

### Ак наз

Ап-ак кышым аяк басты җиргә
Сагындырып, шактый көттереп.
Алсу, көләч булсын йөзләр, диеп
Әй чеметә салкын өттереп.

Сагындырган кышның салкыннары
Нинди матур кары, бураны!!!
Ак бәс сарган кышкы агачларны
Мин яратам кышкы урманны!!!

...Сокланам мин кышкы аланнарга,
Ераклардан дәшә серле нур:
Гүзәллегем күрми кала күрмә!
Читләп үтмә, якын килеп күр!!!

Тирән көртне ярып юллар алам,
Аклык бирә җанга ышаныч.
Ымсындырып дәшеп торсаң да син
Килеп булмый көн дә, кызганыч.

Салкын хасил иткән үләннәрдән
Бик тә күркәм чәчәк бәйләме.
Күз камашыр аклык дөньясы бу -
Җир-әнкәнең сафлык бәйрәме.

Ап-ак кышым аяк басты җиргә,
Сафлык бөрәм җанга ак кардан.
Күңел җырын көйли, тәэсирләнеп,
Ак кыш бүләк иткән ак наздан.

***Гөлназ Мирзасалихова,***
***башлангыч класслар***
***укытучысы***

### Рәнҗетмәгез табигатьне!

Нинди гүзәл, нинди матур,
Туган – үскән җиребез!
Гөл чәчәкле болыннары
Тәмле чишмә суыбыз.

Ык буйлары яшел чирәм,
Хәтфә юрган ябынган.
Сикереп уйный балыклары -
Гүя туймый суыннан.

Җәйге кичләр бигрәк матур,
Яшьләр килә болынга.
Ял итәләр учак ягып
Урман, елга буенда.

Кайчакларда артларыннан
Кала өелеп чүпләре.
Табигатьне рәнҗеткәнен
Аңламый шул күпләре.

Чишмәләрдән су эчәләр
Сусауларын басарга.
Суы саекмасын дисәң,
Пычратма син аны.

Агачларны сындырмагыз,
Чисталыкны саклагыз!
Таптамагыз чәчәкләрне,
Ташламагыз чүпләрне.

Табигатьне саклагыз, сез!
Булмагыз, сез, битараф!-
Диеп кычкырасым килә,
Тирә-ягыма карап.

***Харисов Илназ,***
***4 нче б сыйныфы укучысы***



### Кышның бер көне

Менә нинди кар яуды,
Ап-ак булды җир өсте.
Чаналарга, чаңгыларга
Җиткереп булмый эшне.

Чаж да чож чаңгы шуа
Кечесе һәм олысы.
Тау буйлары гөр килә,
Кышның килде карлысы!

***Хисамова Нәзилә,***
***4 нче б сыйныфы укучысы***

### Кышкы матурлык

Кышлар да үтте инде,
Яз китерде Нәүрүз.
Иминлек теләп көнгә
Әйдә, безнең өйгә уз!

Кыш бабай һәм Кар кызы
Йөргән иде шат булып.
Аларны каршы алды
Бөтен дөнья ак булып.

Капчык-капчык өләштеләр
Кәнфитләр, прәнникләр.
Алар инде яздан качып
Котыпка ук киттеләр.

***Исмәгыйлова Лиана,***
***4 нче б сыйныфы укучысы***

### Кышны озату

Озатам сине, кышым,
Зарыгып көткән идек,
Чаңгы шуып, бозда уйнап
Күнегеп беткән идек.

Агачлар ак бәс иде,-
Кабатланмас матурлык!
Язга каршы торалмас,
Булса да батыр һәм нык.

***Солтанов Илшат,***
***4 нче б сыйныфы укучысы***

## ФОТОРЕПОРТАЖ

















КОТЛЫЙБЫ

### “ТЫЛСЫМ+” ГАЗЕТАСЫ - РЕСПУБЛИКА КОНКУРСЫ ҖИҢҮЧЕСЕ

“ТЫЛСЫМ+” мөхәрриятен “Әдәбият елы” на багышлап чыгарылган мәктәп һәм студенлар газеталары республика конкурсында беренче урын яулавы белән котлыйбыз. Каләмегез үткен, тылсымлы булсын, кызыклы сәхифәләрегез белән куандырып торыгыз!

***Гимназия үзидарәсе***

ТЫЛСЫМ+

Декабрь, 2015 нче ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Муллагалиева Алсу, Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Сәфәргалина Инзилә, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Маннанов Илдар
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru